Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы

муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе”Шомбыт урта гомуми белем бирү мәктәбе”

| | | |
|---|---|---|
| ***«КАРАЛДЫ»***<br>Башлангыч сыйныфлар МБ җитәкчесе<br>__________/Фахрутдинова Р.К./<br>Беркетмә № 1<br>«29» август 2015 ел. | ***«КИЛЕШЕНДЕ»***<br>Уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары<br>__________ /Муталлапова Р.Х./<br>«29» август 2015 ел | ***« РАСЛЫЙМ»***<br>Мәктәп директоры __________/Фарзутдинов Р.Х./<br>боерык № 98<br>« __ » август 2015 ел |

«Шумбутская средняя общеобразовательная школа» Для документов

# *Татар теленнән якынча эш программасы*

Фәрзетдинова Вәсилә Таһир кызы

«Перспективалы башлангыч мәктәп» 1 сыйныф

«КАРАЛДЫ»
Педагогик совет утырышында
Беркетмә № 1
«29» август2015 ел.

2015-2016 уку елы

# ГРАМОТАГА ӨЙРӘТҮ
## Аңлатма язу

Эш программасы гомуми белем бирү дәүләт стандарты федераль компоненты (2009 г.), “ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ тарафыннан тәкъдим телгән **Ф.Ш.Гарифуллина, И.Х.Мияссарова, Р.Р.Шәмсетдинова** авторлыгындагы “**ГРАМОТАГА ӨЙРӘТҮ ПРОГРАММАСЫ**”( Казан “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, “, 2012ел) һәм мәктәпнең 2015-2016 нчы уку елы планына нигезләнеп төзелде.

Программа яңа укыту стандартлары таләпләрен искә алып, үстерешле укыту принциплары белән традицион белем бирү принципларының үзара тыгыз бәйләнештә булуын тәэмин итә торган «Перспективалы башлангыч мәктәп» концепциясенә нигезләнеп эшләнгән.

**Курсның максаты —** укучыларны татар теленең график системасы төзелеше һәм функциясенең гомуми закончалыклары белән танышу нигезендә башлангыч уку һәм язуга өйрәтү. Бу үз чиратында укучыларда тел турында белем һәм күнекмәләрнең формалашуына нигез булып тора.

**Татар теле укытуның максаты :**

- укучыларның фикерләү сәләтен үстерү, тел чараларын аралашуның эчтәлегеннән чыгып билгели белү, балаларның ана телендә аралашу күнекмәләрен камилләштерү;

- телнең фонетика, лексика, грамматикасы буенча башлангыч белем алу, өйрәнелә торган тел берәмлекләрен тикшерә белү күнекмәләрен булдыру,

- дөрес уку һәм дөрес язу күнекмәләрен булдыру, диалогик сөйләмдә катнашу, гадирәк итеп төзелгән монологик сөйләм оештыру;
- укучыларда ана теленә хөрмәт һәм ярату тәрбияләү, телнең чисталыгын, дөреслеген саклау, тел өйрәнүгә кызыксыну өйрәтү.

I сыйныфта балалар укырга өйрәнү белән параллель язарга да өйрәнә. Укудан аермалы буларак, язу кул хәрәкәте компоненты булып тора. Язуның график күнекмәләре (хәрефләрнең рәвешләрен, тоташ язу, язу тизлеген үзләштерү) — хәрәкәт күнекмәләренең бер төре. Язу процессында һәр авазның язма хәрефен күңелдә тудырырга, бу очракта шул аваз нинди хәреф билгесе белән белдерелүен искә төшерергә һәм кул чугы мускулларын хәрәкәтләндереп, шул хәрефне дөрес язарга кирәк. Катлаулы кул хәрәкәте эшчәнлеге буларак, язуны автоматлашу дәрәҗәсенә җиткерү нәтиҗәсендә график күнекмә барлыкка килә.

Язарга өйрәтү, уку кебек үк, өч (әзерлек, төп (аваз-хәреф) һәм йомгаклау) этаптан тора.

Әзерлек этабында I сыйныф укучылары график системаның структур берәмлекләре, яки татар алфавитының язма хәрефләре элементлары белән таныша. Язарга өйрәнүнең төп этабында (ул әлифба чорына туры килә) балалар барлык язма хәрефләрне иҗекләрдә, сүзләрдә, җөмләләрдә кушып (тоташ) язу күнекмәләрен алалар.

Йомгаклау этабында балаларның язуларындагы график һәм каллиграфик хаталар төзәтелә, график күнекмәләр ныгытыла.

***Программа эчтәлеге***

***Әзерлек чоры***

**Язу**

Язганда дөрес утыру һәм язу әсбапларын дөрес куллану кагыйдәләре белән танышу. Дәфтәр битләрендә ориентлашу, андагы сызыклар белән танышу. Вертикаль, горизонталь һәм авыш сызыклар турында белешмә.

Татар алфавиты хәрефләре график системасының структур берәмлеге буларак кулланылган элемент-сызыклар. Алгоритм буенча элемент-сызыкларны язу. Язма хәрефләрнең өлге формалары белән танышу. Бордюр-бизәкләр ясау процессында язма хәреф элементлары турында күзаллау тудыру.

График системаның структур берәмлеге булган язма хәреф элементларын чагыштыру, төркемләү һәм йомгаклау, гомуми нәтиҗә ясауга корылган логик күнегүләр үтәү.

**Әзерлек чоры ахырына балалар**:

1. Элементар образлы күзаллау дәрәҗәсендә тел берәмлекләре: сүз, җөмлә, текстны **аңлый**, шулай ук татар алфавитының басма һәм язма хәрефләр системасын **атый һәм формалары буенча аера белергә**;.

2. Рәсем, график модель яки тиешле фишкалар кулланып, беренчедән, дәрестә тудырылган тел ситуацияләре буенча 2 — 4 сүздән торган **җөмләләр** һәм 3 — 4 җөмләдән торган **хикәя төзи**; икенчедән, парта артында **дөрес утыра** һәм язма әсбаплардан дөрес **файдалана**, алгоритм буенча яки тактлап язма хәрефләрнең барлык элементларын да **дөрес яза белергә тиешләр.**

***Әлифба чоры***

**Язу**

Дөрес утыру һәм язу әсбапларын дөрес куллану кагыйдәләре.Дөрес утыру һәм язу әсбапларын дөрес куллану күнекмәләрен камилләштерү.

Уку дәресләрендә элемент-өлгеләр ярдәмендә басма хәрефләрне төзү күнегүләре. Балалар хәтерендә барлык басма хәрефләрнең күрмә образларын формалаштыру.

Язу дәресләрендә элемент-өлгеләрдән язма хәрефләр төзү һәм анализлау. Гомуми уртак элемент формалары буенча хәрефләрне төркемләү һәм чагыштыру буенча логик биремнәр үтәү.

Балалар хәтерендә язма баш һәм юл хәрефләренең төгәл күрмә-хәрәкәтле образларын формалаштыру. Бу хәрефләрне алгоритм һәм тактлап (санап) язу технологиясен камилләштерү.

Язуда оч төрле (өске, урта-йөзмә, аскы) тоташтыру алымы белән танышу.Дәрестә өйрәнелә торган хәрефне элек өйрәнелгән хәрефләр белән тоташтыру алгоритмнарын үзләштерү.

Тактлап язу алымы нигезендә кул чугы мускуллары киеренкелеген йомшарту (киметү) белән ритмик чиратлаштыру күнегүләре.

Сүзнең аваз схемасын график формага үзгәртү һәм алга таба язма хәрефләр белән язу. Язма хәрефләр белән бирелгән иҗек, сүз, җөмлә үрнәкләрен уку. үрнәк буенча язу. укучыларның үз язуларының нәтиҗәләрен тикшерүләре.

**Әлифба чорының ахырына балалар:**

1. Татар теленең авазларының сузык (ачык авыз символы белән бирелгән), ягъни җырлана торган аваз һәм тартык, ягъни җырланмый торган; әйткәндә, сөйләм органнарында киртә ясала/ясалмый торган авазларга бүленүен, сузыкларның калын һәм нечкә булуын, тартыкларның нечкә- калын яңгырашын сузык аваз хәрефләре белдерүен;

- сүзнең яңгыраш һәм мәгънә бөтенлегенә ия булуын;
- сүзнең иҗекләргә бүленүен, бер иҗекнең көчлерәк һәм озынрак әйтелүен;
- сөйләм авазлары язуда шартлы график символлар (түгәрәк, квадрат) яки хәрефләр белән белдерелүен;
- сүзләр предметларны, аларның билгеләрен, эш-хәрәкәтләрен белдерүләрен, ярдәмче сүзләр сүзләрне, җөмләләрне үзара бәйләү өчен хезмәт итүләрен, аларның график символларын;
- әйтмә сөйләмнең текст һәм җөмләләргә бүленүен, аларны график сурәтләп булу мөмкинлеген;

элемент-сызыклар һәм элемент-өлгеләрнең басма һәм язма хәрефләрнең график системасының структур (төзелеш) берәмлекләре булуын;

- һәр басма һәм язма хәреф формасының тиешле урын-сан мөнәсәбәтендә урнашкан элементлардан торуын **аңлый белергә тиеш.**

2. Укучылар сүз башыннан башлап, андагы һәр авазны көчлерәк итеп **билгели бара**, берсен аерып алып аңа **характеристика бирә**;

- анализ вакытында тартыкларның яңгырау-саңгыраулыгын билгеләү алымнарын **куллана;**
- сүзне иҗекләргә **бүлә**;
- схемалардан сүзнең аваз язылышын иҗекләп һәм орфоэпик **дөрес итеп укый**;
- схемалардагы һәм «Әлифба» текстларында бирелгән хәреф язуын иҗекләп һәм орфоэпик дөрес итеп **укый;**
- сүзнең аваз формасын шартлы график формадан хәреф формасына һәм киресенчә **үзгәртә;**

- элемент-шаблоннар нигезендә басма һәм язма хәрефләрне **төзи һәм анализлый;**

- аерым график биремне үтәү дәвамында дөрес итеп утыра һәм язма әсбаплардан **файдалана ала;**

- билгеле бер алгоритм буенча хәрәкәт элементлары нигезендә хәрефләр **яза;**

- иҗекләрдә һәм сүзләрдә тоташтыруның өч алымын **үти;**

- тактлап язганда кул чугы мускуллары киеренкелеген **йомшарта;**

- күчереп язганда һәм диктант вакытларында җөмләләрне һәм үз исемнәрен **дөрес яза;**

- бизәк-бордюрлар **ясый ала белергә тиешләр**.

***<u>Әлифбадан соңгы чор</u>***

Алгоритм буенча сүзләрдә язма хәрефләрнең һәм аларны тоташтыру сызыкларын язу технологиясен ныгыту.

Тактлап язганда кул чугы мускуллары киеренкелеген йомшару халәте белән чиратлаштыра белү. График хаталарны төзәтү һәм каллиграфик язу сыйфатын камилләштерү эшләре. Тизләтелгән темпта язу шартларында график грамоталылыкны һәм каллиграфик сыйфатны формалаштыру. Язма һәм басма текстлардан сүз һәм җөмләләрне күчереп язу. әйтеп яздыра торган текстны язу.

**Грамотага өйрәтүнең йомгаклау чорында беренче сыйныф укучылары:**

1. Туган телнең сөйләм төзелешен **аңлый**, аваз, иҗек, сүз, сүзтезмә, җөмлә, текст кебек тел берәмлекләрен образлы **күзаллый**;

- татар алфавиты басма һәм язма **хәрефләренең график системасын**;

- һәр хәрефнең элемент **формаларын;**

- дөрес утыру һәм язма әсбапларны куллану **кагыйдәләрен белергә тиеш.**

2. Һәр укучы үзенә генә хас темпта басма һәм язма текстларны офоэпик нормаларга туры китереп **укый;**

- текстның аерым бер өлешләрен **сөйли** (2 — 3 җөмлә белән);

- укылган текст эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга **җавап бирә;**

- тыңланган текстка **исем куша**;

- төрле методик шартларда: 1) басма яки язма текстны күчереп язганда, 2) хәтер буенча яки 3) укытучы әйтеп яздырган вакытта, үзләштерелгән алгоритмга туры китереп аерым да, җөмлә эчендә дә сүзләрне өзмичә **язу күнекмәләрен үзләштерә** һәр укучы, шәхси мөмкинчелеген истә тотып, **язу темпын арттыра белү кебек эш төрләрен башкара белергә тиеш**.

3**. О, ө** хәрефләрен беренче иҗектә генә **язу;**

- әйтмә һәм язма сөйләмне тел берәмлекләренең төзелеше турында беренче сыйныф укучыларында формалашкан күзаллау нигезендә **анализлау** һәм тиешле символлар белән **модельләштерү;**

- тыныш билгеләренә игътибар итеп. иҗекләп, орфоэпик, бәйләнешле итеп уку алымнарын **куллану;**

- хәрефләрне язуда тоташ һәм тиз итеп язу алымнарын **тормышка ашыру**;

- татар теленең позицион принцибына нигезләнеп, **[гь] [кь]** авазларын язуда **белдерү** турында **үзләштергән белем һәм күнекмәләрен уку эшчәнлегендә һәм көндәлек тормышта кулланырга өйрәнергә тиешләр.**

**Укыту-методик чаралар**: Язарга өйрәнү дәфтәрләре №1,2 . Казан: "Мәгариф-Вакыт" нәшрияты, 2012 ел.

**Күрсәтмәлелек.** Язу элементлары күрсәтелгән битләр, язма хәрефләр, алфавит, «Авазлар һәм хәрефләр» таблицасы, авыр язылышлы сүзләр, сүзлекләр, таблицалар: «Җөмлә.Сүз. Иҗек.Аваз», сюжетлы рәсемнәр, ребуслар, табышмаклар, мәкальләр.

**Татар теле**

Атналык сәгатьләр саны: 3 (татар теле)

Еллык сәгатьләр саны: 99

I-чирек (18 дәрес)

II-чирек (14 дәрес)

III-чирек (9+10 дәрес)

IV – чирек (15 дәрес)

| № | Эчтәлек | Сәгать саны |
|---|---|---|
| | Грамотага өйрәтү (язу) | |
| 1 | Әзерлек чоры | 9 |
| 2 | **<u>Әлифба чоры :</u>**<br>Сузык [а, ә, ы, э, и, у, ү, о, ө] авазлар<br>[м, н, л, р, й, ң] сонор тартык авазлары.<br>Я, е, ю хәрефләренең ике авазга [йа], [йә], [йы], [йә], [йу], [йү] билге булып килүләре<br>Яңгырау һәм саңгырау парлары булган тартыклар<br>Аеру билгеләре булып торган ь һәм ъ<br>Парсыз тартык авазлар | **64** |
| 3 | Әлифбадан соңгы чор | |
| | **Татар теле** | **35** |
| | Алфавит | |
| | Җөмлә. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Балалар сүзләр белән таныша. | |
| | Телдән һәм язма сөйләм серләре. | |
| | Авазлар һәм хәрефләр | |
| | Иҗек. | |
| | Барлыгы: | 99 |

**Татар теле**

**Аңлатма язуы**

Укучыларны татар теленә өйрәтүнең төп максаты һәм бурычлары:

1. Укучыларда ана телен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш, эзләнергә теләк уяту, үз милләтенә, теленә мәхәббәт тәрбияләү кебек уңай сыйфатлар булдыру.
2. Балаларга татар теленең төрле бүлекләре буенча белем бирү:

а) фонетика, лексика, грамматикага караган башлангыч мәгълүмат бирү;

ә) телебезнең орфоэпиясе, лексикасы, грамматикасы, пунктуациясе буенча күнекмәләр булдыра башлау. Хәрефләрдән иҗекләр һәм сүзләр, сүзләрдән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзергә өйрәтү.

3. Укучыларны дөрес һәм матур итеп укырга, укыганның эчтәлеген сөйләргә, аерым темалар буенча әңгәмәләр кора белергә, аралашканда тел чараларыннан урынлы файдаланырга өйрәтү.
4. Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләре булдыру.
5. Укучыларда татар мәдәниятенә караган мәгълүматлылыкны үстерү.

**Программаның эчтәлеге**

**Алфавит**

Хәрефләрне дөрес итеп уку(әйтү). Алфавиттагы хәрефләрнең урынын белү. Китапларны киштәләргә авторларының баш хәрефләренә карап урнаштыра белү. Сүзлекләр төзүдә алфавитны белүнең әһәмиятен аңлау.

**Авазлар һәм хәрефләр.** Сузык һәм тартык авазлар. Калын һәм нечкә сузыклар, аларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы. Авазларның калынлыкта-нечкәлектә ярашуы.

Иҗекләрне һәм сүзләрне дөрес уку һәм язу. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, аларны юлдан юлга күчерү. Сүзне тиешле басым белән әйтү(уку).

Яңгырау һәм саңгырау тартыклар, аларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы. Парлы һәм парсыз яңгырау һәм саңгырау тартыклар.

**Предмет** атамасын белдергән сүзләр – исемнәр белән таныштыру. Аларның мәгънәләрен аңлату, сорауларын әйтү; уртаклык һәм ялгызлык исемнәр һәм аларның язылышы. Исемнәр янында кулланыла торган ярдәмче сүзләр – бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр белән таныштыру.

Предметның **билгесен белдергән** сүзләр белән таныштыру.

**Эш-хәрәкәтне** белдергән сүзләр – фигыльләр белән таныштыру.

**Телдән һәм язма сөйләм.** Телдән сөйләмнең үзенчәлекләре(интонация, сүз басымы). Язма сөйләм үзенчәлекләре(җөмлә башында, ялгызлык исемнәрдә баш хәреф). Анда сүзнең *кем?* яки *нәрсә?* турында баруын һәм алар хакында нинди яңалык хәбәр ителүен төзү. Төрле интонация белән әйтелгән җөмләләрдән соң куелган тыныш билгеләре.

Әзер тексттан сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне дөрес итеп күчереп язу. Аннан соң аларны укытучы әйтүе буенча язу, ул тәкъдим иткән сүзләрдән сүзтезмә һәм җөмләләр төзү.

Аерым темалар буенча өйрәнгән сүзләрне, сүзтезмә һәм җөмләләрне диктант итеп язу. Матур язу күнегүләрен үтәү. Сөйләм күнекмәләре булдыру өстендә даими эшләү.

**1 нче сыйныф укучыларының белем дәрәҗәләрендә булачак нәтиҗәләр**

- аваз һәм хәрефләрне танып белү, аларның аермасын аңлатып бирү (авазны әйтәбез, ишетәбез, сүзләр авазлардан тора; хәрефне күрәбез, таныйбыз, язабыз, укыганда шул хәрефнең авазын әйтәбез);
- сүзләрнең мәгънәсен аеруда авазларның әһәмиятен гамәли аңлау (авыз, авыл, авыр; биш, баш, буш);
- авазларны сузык һәм тартыкларга аеру, аларны сүздән тыш та ачык һәм дөрес әйтү; тартык һәм сузык авазлар арасындагы аермалык нигезен аңлау һәм шуны аңлату; калын һәм нечкә сузыкларның үзлеген белү, укыганда, сүзләрнең калын һәм нечкә әйтелешен сайлау өчен, шул үзлектән файдалану;
- татар алфавитын яттан белү, алфавитның әһәмиятен аңлау һәм аңлату;
- баш һәм юл хәрефләрен, аларны тоташтыручы сызыкларны аермачык, бозмыйча язу; сүзләрне матур, дөрес, хәрефләрне төшереп калдырмыйча, өстәмичә, урыннарын алыштырмыйча язу;
- сүзләрне иҗекләргә бүлү, авазларга таркату, иҗек санын сузык авазларга мөнәсәбәтле итеп билгеләү; сүз басымын ишетеп билгеләү;
- предмет, эш-хәрәкәт, билге атамалары булган сүзләрне сораулар куеп аера, төркемләштерә белү, аларның сөйләмдәге ролен гамәли аңлау;
- җөмләне сүздән, сүзтезмәдән аера белү; язганда, җөмләнең башын һәм азагын дөрес күрсәтү;
- әйтелеше белән язылышы туры килгән 3-5 сүзле җөмләне ишетеп язу;
- беренче сыйныфта өйрәнгән күләмдә авазларга характеристика бирү;
- сүзне, җөмләне, текстны схема яки модель итеп күрсәтә белү;

- укытучы һәм сыйныфташлар белән кара-каршы әдәпле сөйләшү;
- балаларның яшь үзенчәлекләренә туры килгән табышмакларның җавабын табу, кыска мәкаль-әйтемнәрне сөйләмдә куллану.

**Татар теленнән тематик – календарь планлаштыру**

| № | Дәрес темалары | Сәг. саны | Дәрес тибы | Уку-укыту эшчәнлегенең төрләре | Материалны үзләштерү буенча планлаштырылган нәтиҗәләре | | | Контроль төре төрләре. | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Шәхес | Метапредмет | Предмет | | План | Факт |
| **I-чирек (18 дәрес) Әзерлек чоры (9сәг.)** | | | | | | | | | | |
| 1. | Кереш дәрес. Язу дәфтәре белән танышу. | **1** | Кереш дәрес | Язганда дөрес утыру һәм язу әсбапларын дөрес куллану кагыйдәләре белән танышу. Дәфтәр битләрендә ориентлашу, андагы сызыклар белән танышу. Вертикаль, горизонталь һәм авыш сызыклар турында белешмә.Татар алфавиты хәрефләре график системасының структур берәмлеге | Укучы ролен үзләштерү. Уку һәм таныпбелүгә битараф булмау . | ТБУУГ: логик гамәлләр куллану: чагыштыру, гомумиләштерү, аналогия, анализ һәм синтез КУУГ: үз фикерен әйтә белү РУУГ: үз эшчәнлекләре барышында контроль ясый белү | **Белергә тиеш:** интервалны саклап нокталарны дөрес итеп кую, ручканы дөрес тоту, авышлыкны дөрес итеп бирүне **Башкара алырга тиеш:** нокталар куюны һәм туры, астан элмәкле туры сызыклар сызуны | Агымдагы. | 02.09 | |
| 2. | Вертикаль, горизонталь һәм авыш сызыклар турында белешмә. | | Яңа материал өйрәнү | | Укуга карата кызыксыну хисе булу. | ТБУУГ: логик гамәлләр куллану: чагыштыру, гомумиләштерү, аналогия, анализ һәм синтез КУУГ: үз эшчәнлеген оештыру өчен сорау бирә белү | **Белергә тиеш:**дәфтәрләрдә эшләү кагыйдәләрен, авышлыкны дөрес итеп бирүне **Башкара алырга тиеш:**астан элмәкле | | 02.09 | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | буларак кулланылган элемент-сызыклар. Алгоритм буенча элемент-сызыкларны язу. Язма хәрефләрнең өлге формалары белән танышу. Бордюр-бизәкләр ясау процессында язма хәреф элементлары турында күзаллау тудыру. График системаның структур берәмлеге булган язма хәреф элементларын чагыштыру, төркемләү һәм йомгаклау, гомуми нәтиҗә ясауга корылган логик күнегүләр үтәү. | | РУУГ: бирем үтәүнең максатын укытучы җитәкчелегендә билгеләү, аңа ирешергә тырышу | туры сызыклар сызуны | | | |
| 3. | Язма хәреф элементларын дөрес язарга өйрәнү: туры сызык. | **1** | Яңа материал өйрәнү | | Укучының социаль ролен кабул итү | ТБУУГ: логик гамәлләр куллану: чагыштыру, гомумиләштерү, аналогия, анализ һәм синтез КУУГ: сөйләм чараларыннан дөрес һәм урынлы куллану РУУГ: үз эшчәнлекләрен анализлый белү | **Белергә тиеш:**дәфтәрләрдә эшләү кагыйдәләрен, авышлыкны дөрес итеп бирүне **Башкара алырга тиеш:**астан элмәкле туры сызыклар сызуны | Агымдагы. Үз-үзеңне бәяләү. | 03.09 | |
| 4. | Язма хәреф элементларын дөрес язарга өйрәнү:, бер яктан ыргаклы туры сызык. | | Яңа материал өйрәнү | | Уку һәм танып-белүгә мотивация | КУУГ: төркемдә үзара ярдәм итешү. Мәгълүмат эзләү, дискуссиядә катнашу. РУУГ: үз гамәлләреңне һәм аның нәтиҗәләрен бирелгән үрнәк белән чагыштыру. | **Белергә тиеш:**дәфтәрләрдә эшләү кагыйдәләрен, авышлыкны дөрес итеп бирүне **Башкара алырга тиеш:**астан элмәкле туры сызыклар сызуны | | 08.09 | |
| 5. | Ике яктан элмәкле, икенче яктан ыргаклы туры сызык. Элмәкле | **1** | Яңа материал өйрәнү | | Уку һәм танып-белүгә мотивация | КУУГ: төркемдә үзара ярдәм итешү. Мәгълүмат эзләү, дискуссиядә катнашу. РУУГ: үз гамәлләреңне һәм аның нәтиҗәләрен бирелгән үрнәк белән чагыштыру. | **Белергә тиеш:**дәфтәрләрдә эшләү кагыйдәләрен, авышлыкны дөрес итеп бирүне | Агымдагы. Үрнәк буенча | 09.09 | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | йөзмә сызык язу. | | | | | | **Башкара алырга тиеш:**астан элмәкле туры сызыклар сызыну | тикшерү. | | |
| 6. | Бер яктан элмәкле, икенче яктан ыргаклы туры сызык, элмәкле йөзмә сызык язу. | **1** | Катнаш | | Тырышлык һәм хезмәт сөючәнлеккә бәйләп, укудагы уңышлары (уңышсызлыклары) турында бәя бирәләр. | ТБУУГ: логик гамәлләр куллану: чагыштыру, гомумиләштерү, аналогия, анализ һәм синтез КУУГ: үз фикерен әйтә белү РУУГ: үз эшчәнлекләре барышында контроль ясый белү | **Белергә тиеш:**дәфтәрләрдә эшләү кагыйдәләрен, авышлыкны дөрес итеп бирүне **Башкара алырга тиеш:**астан элмәкле туры сызыклар сызыну | Агымдагы. Үзара тикшерү. | 10.09 | |
| 7. | Озынча түгәрәк, ярымозынча түгәрәк язу. | **1** | Яңа материал өйрәнү | | Үзлегеңнән камилләшүнең кирәклеген аңлау | ТБУУГ: логик гамәлләр куллану: чагыштыру, гомумиләштерү, аналогия, анализ һәм синтез КУУГ: үз фикерен әйтә белү РУУГ: үз эшчәнлекләре барышында контроль ясый белү | **Белергә тиеш:**сүзләрне иҗекләргә бүлү ысулларын **Башкара алырга тиеш:**.овал формасындагы фигураларны дөрес итеп ясый белүне | Агымдагы. Үз-үзеңне бәяләү | 15.09 | |
| 8. | Хәреф элементлары язу | **1** | Катнаш | | Үзлегеңнән камилләшүнең кирәклеген аңлау.үз белемең һәм белмәгәнеңнең чикләре әһәмиятен | ТБУУГ: логик гамәлләр куллану: чагыштыру, гомумиләштерү, аналогия, анализ һәм синтез КУУГ: үз фикерен әйтә белү РУУГ: үз эшчәнлекләре барышында контроль ясый | **Белергә тиеш:**сүзләрне иҗекләргә бүлү ысулларын **Башкара алырга тиеш:**.овал формасындагы фигураларны дөрес итеп ясый белүне | | 16.09 | |
| 9. | Хәреф элементлары язу | **1** | Катнаш | | | | | | 17.09 | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | аңлыйлар. | белү | | | | |
| **Әлифба чоры (55сәг.)** | | | | | | | | | | |
| 10 | Юл а, баш А хәрефләрен язу. | **1** | Яңа матер иал өйрән ү | Дөрес утыру һәм язу әсбапларын дөрес куллану агыйдәләре.Дөрес утыру һәм язу әсбапларын дөрес куллану күнекмәләрен камилләштерү. Уку дәресләрендә элемент-өлгеләр ярдәмендә басма хәрефләрне төзү күнегүләре. Балалар хәтерендә барлык басма хәрефләрнең күрмә образларын формалаштыру. Язу дәресләрендә элемент-өлгеләрдән язма хәрефләр төзү һәм анализлау. Гомуми уртак | Уку һәм танып-белүгә мотивация | КУУГ: тыңлаучыларга аңлаешлы сөйләм төзү, үзара ярдәм итешү.<br>ТБУУГ: модель төзү: текстны тамга-символик телгә күчерү<br>РУУГ: бирем үтәүнең максатын укытучы җитәкчелегендә билгеләү, аңа ирешергә тырышу | **Белергә тиеш:**авазлар һәм хәрефләрнең аермасын<br>**Башкара алырга тиеш:**а хәрефен график дөрес яза, тоташтыра белүне | Агым дагы. Үзара тикш ерү. | 22.09 | |
| 11 | Юл ә, баш Ә хәрефләрен язу. | **1** | Яңа матер иал өйрән ү | | Уку һәм танып-белүгә мотивация | КУУГ: төркемдә үзара ярдәм итешү.<br>Мәгълүмат эзләү, дискуссиядә катнашу.<br>РУУГ: үз гамәлләреңне һәм аның нәтиҗәләрен бирелгән үрнәк белән чагыштыру | **Белергә тиеш:**баш һәм юл хәрефләренең язылышын<br>**Башкара алырга тиеш:**баш һәм юл хәрефләрен, аларны тоташтыручы сызыкларны һәм сүзләрне ачык итеп, бозмыйча язу; | Агым дагы. | 23.09 | |
| 12 | Юл ә, баш Ә хәрефләрен язу. | **1** | Яңа матер иал өйрән ү | | | | | | 24.09 | |
| 13 | Юл ы, баш Ы хәрефләрен язу. | **1** | Яңа матер иал өйрән | | Үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга | ТБУУГ: логик гамәлләр куллану: чагыштыру, гомумиләштерү, аналогия, анализ һәм синтез | **Белергә тиеш:**аваз һәм хәрефне аера<br>**Башкара алырга тиеш:** баш һәм юл | | 29.09 | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | ү | элемент формалары буенча хәрефләрне төркемләү һәм чагыштыру буенча логик биремнәр үтәү.<br>Балалар хәтерендә язма баш һәм юл хәрефләренең төгәл күрмә-хәрәкәтле образларын формалаштыру. Бу хәрефләрне алгоритм һәм тактлап (санап) язу технологиясен камилләштерү.<br>Язуда оч төрле (өске, урта-йөзмә, аскы) тоташтыру алымы белән танышу.Дәрестә өйрәнелә торган хәрефне элек өйрәнелгән хәрефләр белән тоташтыру алгоритмнарын | ихтыяҗ формалашты ру | КУУГ: үз эшчәнлеген оештыру өчен сорау бирә белү<br>РУУГ: бирем үтәүнең максатын укытучы җитәкчелегендә билгеләү, аңа ирешергә тырышу | хәрефләрен, аларны тоташтыручы сызыкларны һәм сүзләрне ачык итеп, бозмыйча язу; | | | |
| 14 | Юл э, баш Э хәрефләрен язу. | **1** | Яңа матер иал өйрән ү | | Үз эшчәнлегене ң нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалашты ру | КУУГ: тыңлаучыларга аңлаешлы сөйләм төзү, үзара ярдәм итешү.<br>ТБУУГ:авазларны аеру өчен модельләрне чагыштыру, яңа хәреф билгеләнешен өйрәнү | **Белергә тиеш:**аваз һәм хәрефне аера<br>**Башкара алырга тиеш:** баш һәм юл хәрефләрен, аларны тоташтыручы сызыкларны һәм сүзләрне ачык итеп, бозмыйча язу; | | 30.09 | |
| 15 | Юл э, баш Э хәрефләрен язу. | **1** | Катна ш | | Үз эшчәнлегене ң нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалашты ру | ТБУУГ: логик гамәлләр куллану: чагыштыру, гомумиләштерү, аналогия, анализ һәм синтез КУУГ: сөйләм чараларыннан дөрес һәм урынлы куллану<br>РУУГ: үз эшчәнлекләрен анализлый белү | **Белергә тиеш:**аваз һәм хәрефне аера<br>**Башкара алырга тиеш:** баш һәм юл хәрефләрен, аларны тоташтыручы сызыкларны һәм сүзләрне ачык итеп, | Агым дагы. Үзара тикш ерү | 01.10 | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | үзләштерү. Тактлап язу алымы нигезендә кул чугы мускуллары киеренкелеген йомшарту (киметү) белән ритмик чиратлаштыру күнегүләре. Сүзнең аваз схемасын график формага үзгәртү һәм алга таба язма хәрефләр белән язу. Язма хәрефләр белән бирелгән иҗек, сүз, җөмлә үрнәкләрен уку. үрнәк буенча язу. укучыларның үз язуларының нәтиҗәләрен тикшерүләре. Алгоритм буенча сүзләрдә язма хәрефләрнең һәм аларны тоташтыру сызыкларын язу технологиясен | | | бозмыйча язу; | | | |
| 16 | Юл и, баш И хәрефләрен язу. | **1** | Яңа материал өйрәнү | | Уку һәм танып-белүгә мотивация | ТБУУГ: логик гамәлләр куллану: чагыштыру, гомумиләштерү, аналогия, анализ һәм синтез КУУГ: әңгәмәдәшне тыңлый һәм диалог алып бара белү РУУГ: уку эшчәнлеге максатын кабул итү, аңа ирешергә омтылу | **Белергә тиеш:**язганда тиешле гигиена таләпләрен **Башкара алырга тиеш:**И и хәрефләрен график дөрес яза белүне, җөмлә яза белүне | Агымдагы. | 06.10. | |
| 17 | Юл у, баш У, хәрефләрен язу. | **1** | Яңа материал өйрәнү | | Уку һәм танып-белүгә мотивация | КУУГ: тыңлаучыларга аңлаешлы сөйләм төзү, үзара ярдәм итешү. ТБУУГ: модель төзү: текстны тамга-символик телгә күчерү. | **Белергә тиеш:**язганда тиешле гигиена таләпләрен **Башкара алырга тиеш:** У,у хәрефләрен график дөрес яза белүне, җөмлә яза белүне | Агымдагы. Үз-үзеңне бәяләү | 07.10 | |
| 18 | Юл ү, баш Ү хәрефләрен язу. | **1** | Яңа материал өйрәнү | | Уку эшчәнлеге барышында сыйныфташлары белән хезмәттәшле | ТБУУГ: логик гамәлләр куллану: чагыштыру, гомумиләштерү, аналогия, анализ һәм синтез КУУГ: үз фикерен әйтә белү РУУГ: үз эшчәнлекләре | **Башкара алырга тиеш:**И,и хәрефләрен график дөрес язуны, кушылмаларны яза белүне; сузык аваз һәм аларның | | 08.10 | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | нығыту.<br>Тактлап язганда кул чугы мускуллары киеренкелеген йомшару халәте белән чиратлаштыра белү.<br>График хаталарны төзәтү һәм каллиграфик язу сыйфатын камилләштерү эшләре. Тизләтелгән темпта язу шартларында график грамоталылыкны һәм каллиграфик сыйфатны формалаштыру.<br>Язма һәм басма текстлардан сүз һәм җөмләләрне күчереп язу. әйтеп яздыра торган текстны язу.<br>Дөрес утыру һәм язу әсбапларын дөрес куллану | к итү | барышында контроль ясый белү | хәрефләренә карап, калын һәм нечкә әйтелгән сүзләрне тану; | | | |
| 19 | Юл у,ү, баш У,Ү хәрефләрен язу. | **1** | Катнаш | | Уку эшчәнлеге барышында сыйныфташлары белән хезмәттәшлек итү | ТБУУГ: логик гамәлләр куллану: чагыштыру, гомумиләштерү, аналогия, анализ һәм синтез<br>КУУГ: үз фикерен әйтә белү<br>РУУГ: үз эшчәнлекләре барышында контроль ясый белү | | | 13.10 | |
| 20 | Юл о, баш О хәрефләрен язу. | **1** | Яңа материал өйрәнү | | Әйләнә-тирәдәгеләргә карата уңай караштa булу<br><br>Уку эшчәнлеге барышында | ТБУУГ: логик гамәлләр куллану: чагыштыру, гомумиләштерү, аналогия, анализ һәм синтез КУУГ: әңгәмәдәшне тыңлый һәм диалог алып бара белү РУУГ: уку эшчәнлеге максатын кабул итү, аңа ирешергә омтылу | **Белергә тиеш:** дөрес язу кагыйдәләрен һәм аларның кулланылышын<br>**Башкара алырга тиеш:** сузык аваз һәм аларның хәрефләренә карап, калын һәм нечкә әйтелгән сүзләрне тану; ө хәрефен, сүзләрне, җөмләләрне график яза белүне | Агымдагы. Үзара тикшерү. | 14.10 | |
| 21 | Юл о, баш О хәрефләрен язу. | **1** | Катнаш | | | КУУГ: төркемдә үзара ярдәм итешү. Мәгълүмат эзләү, дискуссиядә катнашу.<br>РУУГ: үз гамәлләреңне һәм аның нәтиҗәләрен бирелгән үрнәк белән чагыштыру. | | | 15.10 | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | агыйдәләре.Дөрес утыру һәм язу әсбапларын дөрес куллану күнекмәләрен камилләштерү. | сыйныфташлары белән хезмәттәшлек итү | | | | | |
| 22 | Юл ө, баш Ө хәрефләрен язу. | **1** | Яңа материал өйрәнү | Уку дәресләрендә элемент-өлгеләр ярдәмендә басма хәрефләрне төзү күнегүләре. Балалар хәтерендә барлык басма хәрефләрнең күрмә образларын формалаштыру. Язу дәресләрендә элемент-өлгеләрдән язма хәрефләр төзү һәм анализлау. Гомуми уртак элемент формалары буенча хәрефләрне төркемләү һәм чагыштыру буенча логик биремнәр үтәү. Балалар хәтерендә язма баш һәм юл | Үзләренең уңышлары (уңышсызлыклары)ның сәбәпләре турында фикер йөртәләр. | | **Белергә тиеш:**дөрес язу кагыйдәләрен һәм аларның кулланылышын **Башкара алырга тиеш:**сузык аваз һәм аларның хәрефләренә карап, калын һәм нечкә әйтелгән сүзләрне тану; ө хәрефен, сүзләрне, җөмләләрне график яза белүне | Агымдагы. | 20.10 | |
| 23 | Юл ө, баш Ө хәрефләрен язу. | **1** | Катнаш | | | КУУГ: төркемдә үзара ярдәм итешү. Мәгълүмат эзләү, дискуссиядә катнашу. РУУГ: үз гамәлләреңне һәм аның нәтиҗәләрен бирелгән үрнәк белән чагыштыру. | | | 21.10 | |
| 24 | Диктант. (Өйрәнелгән хәрефләр язу) | **1** | Ныгыту | | Уку һәм танып-белүгә мотивация | РУУГ: “Куелган максатка ирешү өчен нәрсәгә өйрәнергә кирәк?”дигән сорауга җавап бирү. ШУУГ: үз мөмкинлекләреңне чамалау, үзеңне читтән күрү | **Белергә тиеш:** сузык һәм тартык авазларны аера **Башкара алырга тиеш:**сүзләрне авазларга таркату; авазларны сүздәге тәртиптә әйтү; н хәрефен, сүзләрне | | 22.10 | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | хәрефләренең төгәл күрмә-хәрәкәтле образларын формалаштыру. Бу хәрефләрне алгоритм һәм тактлап (санап) язу технологиясен камилләштерү. Язуда оч төрле (өске, урта-йөзмә, аскы) тоташтыру алымы белән танышу.Дәрестә өйрәнелә торган хәрефне элек өйрәнелгән хәрефләр белән тоташтыру алгоритмнарын үзләштерү. Тактлап язу алымы нигезендә кул чугы мускуллары киеренкелеген йомшарту (киметү) белән ритмик чиратлаштыру күнегүләре. | | | тоташ яза белүне | | | |
| 25 | Юл н, баш Н хәрефләрен язу. | **1** | Яңа материал өйрәнү | | Уку һәм танып-белүгә мотивация | ТБУУГ: логик гамәлләр куллану: чагыштыру, гомумиләштерү, аналогия, анализ һәм синтез<br>КУУГ: үз эшчәнлеген оештыру өчен сорау бирә белү<br>РУУГ: үз эшчәнлекләре барышында контроль ясый белү | **Белергә тиеш:**сүзләр арасында буш урын калдыру кебек график чараның функциясен аңлый<br>**Башкара алырга тиеш:**Н,н хәрефләрен график дөрес язуны | Агымдагы. | 27.10 | |
| 26 | Юл л, баш Л хәрефләрен язу. | **1** | Яңа материал өйрәнү | | Укучының социаль ролен кабул итү | КУУГ: класс белән эшләгәндә классташлар фикерен исәпкә алып эш итү, күршең белән хезмәттәшлек итү.<br>ТБУУГ: ялгызлык исемнәрендә баш хәреф язу, җөмләдәге сүзләр арасындагы бәйләнешне ачыклау. | **Белергә тиеш:**баш һәм юл хәрефләренең язылышын<br>**Башкара алырга тиеш:Л**л хәрефен график дөрес язуны, басма, кулдан язылган хәрефләр белән бирелгән сүз һәм җөмләләрне дөрес күчереп язу; | Агымдагы. Үзара тикшерү. | 28.10 | |
| 27 | Юл л, баш Л хәрефләрен язу. | **1** | Катнаш | | Үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру. | ТБУУГ: өйрәнгән билге һәм тамгалардан уку максатында файдалана белү<br>КУУГ: үз фикерен әйтә белү<br>РУУГ: үз эшчәнлекләре барышында контроль ясый белү | | | 29.10 | |
| **II-чирек (21 дәрес)** | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 28 | Юл м, баш М хәрефләрен язу. | **1** | Яңа материал өйрәнү | Сүзнең аваз схемасын график формага үзгәртү һәм алга таба язма хәрефләр белән язу. Язма хәрефләр белән бирелгән иҗек, сүз, җөмлә үрнәкләрен уку. үрнәк буенча язу. укучыларның үз язуларының нәтиҗәләрен тикшерүләре. Алгоритм буенча сүзләрдә язма хәрефләрнең һәм аларны тоташтыру сызыкларын язу технологиясен ныгыту. Тактлап язганда кул чугы мускуллары киеренкелеген йомшару халәте белән чиратлаштыра белү. График хаталарны төзәтү һәм | Укучының социаль ролен кабул итү | ТБУУГ: модель төзү, текстны тамга-символик телгә күчерү.<br>КУУГ: уртак эшчәнлектә үзеңә инициатива алу. | **Белергә тиеш:**кеше исемнәрен һәм җөмләләрне язу кагыйдәсен<br>**Башкара алырга тиеш:**Мм хәрефләрен график дөрес язуны, сүзләрне ишетеп язу һәм тикшерү алгоритмын | Агымдагы. Үз-үзеңне бәяләү | 10.11 | |
| 29 | Юл р, баш Р хәрефләрен язу. | **1** | Яңа материал өйрәнү | | Уку эшчәнлеге барышында сыйныфташлары белән хезмәттәшлек итү | ТБУУГ: логик гамәлләр куллану: чагыштыру, гомумиләштерү, аналогия, анализ һәм синтез<br>КУУГ: әңгәмәдәшне тыңлый һәм диалог алып бара белү РУУГ: уку эшчәнлеге максатын кабул итү, аңа ирешергә омтылу | **Белергә тиеш:**сүзләрдә басымлы һәм басымсыз сузык авазларны аера<br>**Башкара алырга тиеш:** юл р хәрефләрен график дөрес язу, шул хәреф кергән сүзләрне язуны, авазларны сүздәге тәртиптә әйтүне | Агымдагы. Үзара тикшерү. | 11.11 | |
| 30 | Ныгыту. Өйрәнгән хәрефләрне язу. | **1** | Катнаш | | Уку һәм танып-белүгә мотивация | ШУУГ: дәрестә үзенең белем һәм күнекмәләрен куллану, үз фикереңне әйтә белү.<br>КУУГ: иптәшеңнең үз-үзен тотышы белән идарә итү, фикерне әйтә белү | | | 12.11 | |
| 31 | Юл й, баш Й | **1** | Яңа | | Үз | ТБУУГ: логик гамәлләр куллану: | **Белергә** | Агым | 17.11 | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хәрефләрен язу | | материал өйрәнү | каллиграфик язу сыйфатын камилләштерү эшләре. Тизләтелгән темпта язу шартларында график грамоталылыкны һәм каллиграфик сыйфатны формалаштыру. Язма һәм басма текстлардан сүз һәм җөмләләрне күчереп язу. әйтеп яздыра торган текстны язу. | эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру | чагыштыру, гомумиләштерү, аналогия, анализ һәм синтез<br>КУУГ: сөйләм чараларыннан дөрес һәм урынлы куллану<br>РУУГ: үз эшчәнлекләрен анализлый белү | **тиеш:**дөрес күчереп язу алымнарын һәм эзлеклелеген<br><br>**Башкара алырга тиеш:**ң хәрефен сүзләрдә дөрес яза белүне, басма, кулдан язылган хәрефләр белән бирелгән сүз һәм җөмләләрне дөрес күчереп язуны; | дагы. Үз-үзеңне бәяләү | | |
| 32 | Юл ң, хәрефләрен язу. | **1** | Яңа материал өйрәнү | | Үз мөмкинлекләреңне чамалау. | РУУГ: кагыйдәләрне истә тоту, шуларга ияреп гамәлләр кылу.<br>ТБУУГ: ялгызлык исемнәрендә баш хәреф язу, җөмләдәге сүзләр арасындагы бәйләнешне ачыклау. | **Башкара алырга тиеш:** Й й хәрефләрен график дөрес язуны, калын һәм нечкә сүзләрне яза белүне; җөмләләрне сүзләргә таркатуны, җөмләдә сүзләрнең урнашу тәртибен үзгәртүне | | 18.11 | |
| 33 | Нығыту. Өйрәнгән хәрефләрне язу күнегүләре. | **1** | Катнаш | | Язуның кирәклеген, системалы язуның мөһимлеген аңлау | РУУГ: кагыйдәләрне истә тоту, шуларга ияреп гамәлләр кылу.<br>ТБУУГ: ялгызлык исемнәрендә баш хәреф язу, җөмләдәге сүзләр арасындагы бәйләнешне ачыклау. | | | 19.11 | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 34 | Юл я, баш Я хәрефләрен язу. | **1** | Яңа материал өйрәнү | | Язуның кирәклеген, системалы язуның мөһимлеген аңлау | ТБУУГ: логик гамәлләр куллану: чагыштыру, гомумиләштерү, аналогия, анализ һәм синтез КУУГ: әңгәмәдәшне тыңлый һәм диалог алып бара белү РУУГ: уку эшчәнлеге максатын кабул итү, аңа ирешергә омтылу | **Белергә тиеш:** . я хәрефенең кулланылышын. **Башкара алырга тиеш:** юл я хәрефен график дөрес язуны, шул кергән сүзләрне ишетеп дөрес язуны, авазларны сүздәге тәртиптә әйтү; | Агымдагы. Үзара тикшерү. | 24.11 | |
| 35 | Юл ю, Баш Ю хәрефләрен язу. | **1** | Яңа материал өйрәнү | | Уку һәм танып-белүгә мотивация | ТБУУГ: логик гамәлләр куллану: чагыштыру, гомумиләштерү, аналогия, анализ һәм синтез КУУГ: әңгәмәдәшне тыңлый һәм диалог алып бара белү РУУГ: уку эшчәнлеге максатын кабул итү, аңа ирешергә омтылу | **Башкара алырга тиеш:** җөмләнең беренче сүзен баш хәреф белән башлап, җөмлә беткәч нокта куеп язу, баш Ю хәрефен график дөрес язуны, калын һәм нечкә сүзләрдә ишетеп дөрес язуны | Агымдагы. | 25.11 | |
| 36 | Юл ю, Баш Ю хәрефләрен язу. | **1** | Катнаш | | Язуның кирәклеген, системалы язуның мөһимлеген аңлау | ТБУУГ: модель төзү: текстны тамга-символик телгә күчерү.<br>КУУГ: тыңлаучыларга аңлаешлы сөйләм төзү, үзара ярдәм итешү | | | 26.11 | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 37 | Юл е, баш Е хәрефләрен язу. | **1** | Яңа материал өйрәнү | | Уку һәм танып-белүгә мотивация | ТБУУГ: логик гамәлләр куллану: чагыштыру, гомумиләштерү, аналогия, анализ һәм синтез<br>КУУГ: үз эшчәнлеген оештыру өчен сорау бирә белү<br>РУУГ: үз эшчәнлеген бәяләү | **Башкара алырга тиеш:** баш Е хәрефен график дөрес язуны, тоташтыруны, шул кергән сүзләрне ишетеп язуны | Агымдагы. Үз-үзеңне бәяләү | 01.12 | |
| 38 | Юл д, баш Д хәрефләрен язу. | **1** | Яңа материал өйрәнү | График хаталарны төзәтү һәм каллиграфик язу сыйфатын камилләштерү эшләре. Тизләтелгән темпта язу шартларында график грамоталылыкны һәм каллиграфик сыйфатны формалаштыру. Язма һәм басма текстлардан сүз һәм җөмләләрне күчереп язу. әйтеп яздыра торган текстны язу. | Уку һәм танып-белүгә мотивация | ТБУУГ: өйрәнгән билге һәм тамгалардан уку максатында файдалана белү<br>КУУГ: әңгәмәдәшне тыңлый һәм диалог алып бара белү РУУГ: уку эшчәнлеге максатын кабул итү, аңа ирешергә омтылу | **Белергә тиеш:** яңгырау авазларны аера<br>**Башкара алырга тиеш:** Д, д хәрефләрен график дөрес язуны, басмачадан күчереп язуны | Агымдагы. | 02.12 | |
| 39 | Юл д, баш Д хәрефләрен язу. | **1** | Катнаш | | Үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру | ТБУУГ: яңгырау һәм саңгырау авазларны анализлый, алар арасындагы охшаш яки аермалы якларны таба белү.<br>РУУГ: укытучы тәкъдим иткән план буенча биремнәр үтәү. | | | 03.12 | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | |
